| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br><br>**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br><br>**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **с. Тюлячи** **КАРАР**

«04» апрель 2022 № 56

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2012 елның 24 апрелендәге 398 номерлы «Хөкем ителүчеләрнең төзәтү һәм мәҗбүри эшләр рәвешендә җәза үтәтү урыннарын билгеләү турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия ФКУ ЖБИ ФҖҮХИ Татарстан Республикасы буенча Арча муниципальара филиалының 2022 елның 23 мартындагы 17/ТО/82/12/3-181 номерлы хатын карап, Россия Федерациясе Җинаять-башкарма кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2012 елның 24 апрелендәге 398 номерлы «Хөкем ителүчеләрнең төзәтү һәм мәҗбүри эшләр рәвешендә җәза үтәтү урыннарын билгеләү турында» карарына (алга таба - карар) (27.01.2014 № 43, 18.02.2016 № 91, 08.11.2016 № 1012, 11.07.2017 № 422, 23.10.2019 № 590, 01.02.2021 № 33, 29.12.2021 № 327 карарлар редакциясендә) үзгәреш кертергә, әлеге карар белән расланган Теләче муниципаль районы территориясендә хөкем ителүчеләрнең төзәтү һәм мәҗбүри эшләр башкару өчен объектлар һәм эш төрләре исемлеген бәян итеп, киләсе редакциядә:

«Теләче муниципаль районы территориясендә хөкем ителүчеләрнең төзәтү һәм мәҗбүри эшләр башкару өчен объектлар һәм эш төрләре исемлеге

| Объект атамасы | Эш төрләре |
|---|---|
| 1. Теләче муниципаль районы Әбде авыл җирлеге Башкарма комитеты.<br>2. Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге Башкарма комитеты.<br>3. Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлеге Башкарма комитеты.<br>4. Теләче муниципаль районы Баландыш авыл җирлеге Башкарма комитеты.<br>5. Теләче муниципаль районы Олы Нырсы авыл җирлеге Башкарма комитеты.<br>6. Теләче муниципаль районы Олы Мишә | - торак пунктлар территорияләрен җыештыру, яшелләндерү, төзекләндерү;<br>- эш биналарын (административ биналарны) җыештыру;<br>- төяү-бушату эшләре;<br>- биналар, корылмалар, юллар ремонт (төзелеш) эшләрен башкарганда ярдәмче эшләр |

| | |
|---|---|
| авыл җирлеге Башкарма комитеты.<br>7. Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлеге Башкарма комитеты.<br>8. Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге Башкарма комитеты.<br>9. Теләче муниципаль районы Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге Башкарма комитеты.<br>10. Теләче муниципаль районы Иске Җөри авыл җирлеге Башкарма комитеты.<br>11. Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Башкарма комитеты.<br>12. Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлеге Башкарма комитеты.<br>13. Теләче муниципаль районы Шәтке авыл җирлеге Башкарма комитеты | |
| 14. ДБУ «Кызыл Йолдыз урман хуҗалыгы».<br>15. ДБУ «Саба укыту-тәҗрибә урман хуҗалыгы» | - урман кисү урыннарында эшләү (визирлар кисү, баганалары ясау һәм урнаштыру);<br>- яшь үсентеләрне карау (ботакларны кисү, чистарту);<br>- урман фонды территорияләрен төзекләндерү ,урман кишәрлекләрен санкцияләнмәгән житештерү һәм куллану калдыкларыннан чистарту, ял итү урыннарын тәртипләү, беседкалар урнаштыру, ауган агачларны җыештыру һ.б.);<br>- урман культуралары житештерү (Колесов жайланмасы белән агач утырту, агач утырту машинасы артыннан үсентеләр биреп бару, урман утырту машинасы артыннан үсентеләр бирү, урман культураларын тулыландыру, урман культуралары мәйданнарын табигый бизәгәндә баганалар әзерләү һәм урнаштыру, урман культураларын агротехник яктан тәрбияләү);<br>- авиация һәм җир өсте ысуллары белән зарарлы организмнар учакларын локальләштерү һәм бетерү эшләрен башкарганда агрегатларга эш эретмәләре белән ягулык салу;<br>- урман янгыннарын җир өсте юлы белән сүндерү |
| 16. «АгроЛак» ЖЧЖ.<br>17. «Алан» ЖЧЖ.<br>18. «Игенче» ЖЧЖ.<br>19. «Август-Теләче» ЖЧЖ.<br>20. «Зиннатуллин Р.А.» ШЭ.<br>21. «Кряж» ЖЧЖ.<br>22. Мифтахов Н.Р. ШЭ.<br>23.Авангард-Строй" ЖЧЖ. | - территорияләрне җыештыру;<br>- төяү-бушату эшләре;<br>- биналар, корылмалар, юллар ремонт (төзелеш) эшләрен башкарганда ярдәмче эшләр;<br>- линия операторы;<br>- биналарны, корылмаларны, юлларны карап тоту эшләре |

| | |
|---|---|
| 24. «Низамов М.Т.» КФХ.<br>25. «ТАН» ҖЧҖ.<br>26. «Әхмәтова Г.Ф.» КФХ | |

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин